РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ГЛАВА ТЮЛЯЧИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

Ленина ул., д. 46, с. Тюлячи, 422080

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

Ленин ур., 46 нчы йорт, Теләче авылы, 422080

тел. (факс): (843) 602-11-89, E-mail: telache@tatar.ru, http://tulachi.tatarstan.ru/


**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

**№ 15** **«10» апреля 2017 г.**

Теләче муниципаль районында «Татарстанның чиста урманнары» республика табигатьне саклау акциясен үткәрү турында»Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 31 мартындагы 605-р номерлы боерыгын тормышка ашыру хакында

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы территориясендә урнашкан урманнарда уңай санитар-экологик хәл булдыру максатыннан, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 31 мартындагы 605-р номерлы «Татарстанның чиста урманнары» республика табигатьне саклау акциясен үткәрү турында» боерыгы нигезендә.

1. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына 2017 елның 25 апреленнән 25 июненә кадәр һәм 15 сентябреннән 15 ноябренә кадәр Теләче муниципаль районы территориясендә «Татарстанның чиста урманнары» республика табигатьне саклау акциясен (алга таба - акция) үткәрүдә ярдәм итәргә.

2. ДБУ "Кызыл Йолдыз урман хуҗалыгы" на (Закирова Г. М.), ДБУ "Саба укыту-тәҗрибә урман хуҗалыгы"на (Сәгъдиев А. Н.) тәкъдим итәргә:

- даими (сроксыз) файдалануга, арендага бирелгән урман кишәрлекләреннән файдаланучылар белән берлектә, түләүсез срокла файдалануга бирелгән, урманнарны каты көнкүреш калдыкларыннан чистарту, коры-сарыдан һәм ауган агачлардан чистарту буенча чаралар күрергә;

урман фонды җирләрендә урнаштырылган беседкалар, мәгълүмат щитлары һәм аншлагларны ремонтлау һәм төзекләндерү;

- «Татмедиа» АҖ филиалы «Теләче информ» мәгълүмат үзәге белән берлектә акцияне массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны тәэмин итәргә.

3. Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнарына акциядә актив катнашырга һәм ведомство буйсынуындагы оешмалар коллективларының урманнарны каты көнкүреш калдыкларыннан чистарту, коры-сарыдан һәм ауган агачлардан чистарту эшләрен оештырырга.

4. Башкарма комитетның яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге яшьләр иҗтимагый берләшмәләрен акциядә катнашуга җәлеп итү буенча эшне оештырырга.

5. Район Башкарма комитетына (Нуруллин Р. Р.), ДБУ "Кызыл Йолдыз урман хуҗалыгы" (Закирова Г. М.), ДБУ "Саба укыту-тәҗрибә урман хуҗалыгы" (Сәгъдиев А. Н.), Ленин участок урманчылыгы (Сагдиев А. Н.) белән берлектә:

- Теләче муниципаль районы территориясендә акция үткәрү планын эшләргә һәм үтәргә;

- акциядә катнашучыларны каты көнкүреш калдыклары полигоннарына чүп чыгару өчен кирәкле транспорт чаралары белән тәэмин итүдә ярдәм күрсәтергә.

6. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

И. Ф. Зарипов